ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ
Ново-Песочная ул., д. 44, г. Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
Ново-Песочная ур. 44 нчы йорт, Казан шәһәре 420107

# БОЕРЫК

28.01.2020 Казан шәһәре № 20-од

2020 елда Татарстан Республикасы
муниципаль архивларының
грант ярдәме алыр өчен бәйгесе турында

Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны тәэмин итүдә, куллануда, аларны исәпкә алу, комплектлаштыру сыйфатын күтәрүдә яңа заман технологияләрен кертү, хәзерге көннең җиһазларын файдаланышка алуны оештыру; архив эше өлкәсендә ныклы югары нәтиҗәләр белән үзләрен танытkan муниципаль архивларга ярдәм итү; аларда уңайлы эш тәҗрибәсен җәйга салу; җитәкчеләр һәм хезмәткәрләрнең профессиональ үсешен тәэмин итү максатында Б О Е Р А М:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме отсын өчен бәйге оештырырга һәм уздырырга (алга таба – бәйге). Сроклары – 2020 елның 27 февраленнән алып 1 апреленә кадәр.

2. 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме отсын өчен бәйге оештырырга һәм уздырырга дигән Нигезләмәне расларга.

3. Архив эшләре һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтү бүлегенә бәйгенең оештыру-методик ягын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Комитетының «2019 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме отсын өчен бәйге оештырырга һәм уздырырга» дигән һәм 02.04.2019 датасы, 85-од номеры белән расланган Боерыгын гамәлдән чыкты дип исәпләргә.

4. Әлеге Боерык рәсми бастырылган көннән гамәлгә керә.

5. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы
Архив эше буенча
Дәүләт комитеты боерыгы
белән 28.01.2020
20-09 номер астында
расланды

2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларын грант ярдәме белән тәэмин итү турындагы бәйге Нигезләмәсе

## I. Гомуми нигезләр

1.1. 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларын грант ярдәме белән тәэмин итү буенча эшләнгән әлеге Нигезләмә «2016-2022 елларда Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан эшләнде. Документ Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан «2016-2022 елларда Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Дәүләт программасы турында» дигән исем белән 395 нче номер астында 10.06.2016 ел датасы белән расланган иде.

Грант отар өчен бәйгедә катнашучылар булып түбәндәгеләр торалар: Грантны гамәлгә куючы (Грант бирүче) һәм Грантны отучы.

Грантны гамәлгә куючы (Грант бирүче) – грантлар бирү буенча хокукы булган Татарстан Республикасының архив эше буенча Дәүләт комитеты.

Грантка дәгъва кылучы – Татарстан Республикасы муниципаль архивы.

Грантны отучы – Татарстан Республикасы муниципаль архивы. Ул әлеге Нигезләмәдәге критерийлар белән таләпләргә тулаем җавап бирә. Муниципаль архив «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклау буенча проектларга ярдәм итү» номинациясендә конкурс сайлавын узып, 1 дән алып 7 нче урынга кадәр чыкты, ә «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын популярлаштыру һәм куллану буенча проектларга ярдәм итү» номинациясендә 1 дән алып 8 нче урынга кадәр урыннарга чыкты. Болар барысы да ошбу Нигезләмәнең 1.6. нчы пунктына туры килә.

Грант диеп әлеге Нигезләмәнең 1.6. нчы пункты нигезендә Грант бирүче тарафыннан җиһазлар һәм җайланмаларны берьюлы тапшыру бәяләнә, алар муниципаль берләшмәләрдәге архив эшен үстерүгә юнәлтелгән чаралар өчен тотылырга тиеш. Грант җиһазлары белән җайланмалары 92-ЗРТ саны белән 2019 елның 30 ноябрендә теркәлгән «Татарстан Республикасының 2020 елгы һәм пландагы 2021-2022 еллары өчен каралган бюджеты, Татарстан Республикасының архив эше буенча Дәүләт комитеты (алга таба – ТР ДАК)

бюджет йөкләмәләре» Татарстан Республикасы Законында каралган чама буенча бюджет ассигнацияләренә алынган булырга тиеш.

1.2. Бәйге ачык характерда һәм, архив эше өлкәсендәге алгарышларны исәпкә алып, коллегиаль принципларга нигезләнеп уздырыла.

1.3. Бәйгегә Грант алучыларны сайлау (алга таба – бәйге сайланышы) Россия Федерациясе Архив фондының документларны комплектлаштыру, аларга исәп-хисап ясау, саклау һәм куллану өлкәсендә яңа заманча техник җиһазлар һәм җайланмалар, алдынгы технологияләр үзләштерүне күздә тотып бирелә. Шулай ук муниципаль архивлардагы уку-укыту, анда эшләүче җитәкчеләр белән хезмәткәрләрнең профессиональ дәрәҗәсен үстерүне дә исәптә тотып гамәлгә ашырыла.

1.4. Бәйге сайланышы вакытында төп бурыч булып Татарстан Республикасы муниципаль берләшмәләрендәге архив эшен җайга салу буенча актуаль һәм колачлы проектларга йөз тоту, яңа технологияләр үзләштерүне исәпкә алу тора.

1.5. Бәйге 2020 елның 27 февраленнән 1 апрельгә кадәр уздырыла. Шулай ук:

2020 елның 27 февраленнән 11 мартка кадәр – Грантка дәгъва кылучы ТР Дәүләт архивына проектларны хат рәвешендә тапшыра.

2020 елның 16 – 27 мартында – Грантка дәгъва кылучы җибәргән хатны проектлар буенча Экспертлар советы әгъзалары карый һәм тикшерә.

2020 елның 31 марты – 1 апрелендә – Грантка дәгъва кылучы проектны экспертлар каршында яклый.

1.6. Бәйге Грантка дәгъва кылучы тапшырган проектлар арасында 2 номинациядә үткәрелә:

| Номинациянең исеме | Грантлар саны | Проектларны тормышка ашыру юнәлешләре | 1 проектка җиһазлау комплекты |
|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклау буенча проектларга ярдәм итү | 7 грант | Заманча архив технологияләрен кулланып, электрон саклавычларда фонд булдыру | 480 000 сумманы тәшкил иткән А 2 форматындагы планетар сканлаштыру автоном комплекс комплекты һәм аңа аксессуарлар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын популярлаштыру һәм куллану буенча проектларга ярдәм күрсәтү | 8 грант | Архив документларын популярлаштыру, куллану мөмкинлекләрен киңәйтү һәм җиңеләйтү (Россия Федерациясе тарафыннан киң кулланылышка чыгарырга рөхсәт ителмәгән документлардан кала), документларны кулланучыларга юл ачу, заманча технологияләрне кулланылышка кертү | 205 000 сумга күргәзмә стендлары, видеопроекторлар комплекты, ноутбуклар, экраннар, аксессуарлар һәм комплектны тулыландыручы җиһазлар |

1.7. Нигезләмә буенча грантка дәгъва кылучылар барлык тәкъдим ителгән номинацияләр буенча да (һәр номинациягә – берәрне) проектлар тапшырырга хокуклы. 2019 елда грант ярдәме алган муниципаль берләшмәләр – чыгарылма. 2019 елдагы конкурс буенча грант отучылар яңа проектларын 2019 елда откан номинацияләргә куя алмый.

1.8. Проектның күтәрелгән проблемасы, куелган максаты, бурычлары булуы зарур, срок ягыннан ул 3 ел дәвамында үтәлергә тиеш. Шулай ук үтәлү урыны, төп чаралар исемлеге, аларның күләме, кыскача тасвирламасы, ирешергә тиешле нәтиҗәләр дә күрсәтелә.

1.9. Бәйгегә тапшырылган проектларга эксперт бәяләмәсе булсын өчен һәм саайлап алуны күздә тотып Экспертлар советы төзелә.

1.10. Бәйге турындагы мәгълүматлар, сроклар, шартлар һәм критерийлар ТР ДАК рәсми сайтында «2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларын грант ярдәме белән тәэмин итү буенча конкурс турында» Боерык чыгарылганнан соң 5 көннән дә калмый урнаштырыла.

## II. Бәйгедә катнашу шартлары һәм документларны тәкъдим итү кагыйдәләре

2.1. Бәйгедә барлык Татарстан Республикасы муниципаль архивлары да катнаша ала.

2.2. Бәйгедә катнашу өчен ТР ДАК на түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

- Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты җитәкчесе кул куйган конкурста катнашу гаризасы (әлеге Нигезләмә кушымтасына ярашлы рәвештә);

- Грантка дәгъва кылучының проектлары;

Гариза белән проектлар ТР ДАК на әлеге Нигезләмәнең икенче абзацында 1.5. нче пунктта күрсәтелгән срокларда Татарстан Республикасы ведомствоара Бердәм электрон документ тапшыру системасы ярдәмендә тапшырыла. Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты җитәкчесе язган хат та беркетелгән булырга тиешле.

2.3. Әгәр проектка аудио- яисә видеоматериаллар беркетелгән булса, аларны почта аша юлларга мөмкин. ТР ДАК ның электрон адресына prm.archive@tatar.ru юлланган хатлар шул ук көнне ТР ДАК на бәйгедә катнашыр өчен тапшырыла.

2.4. Бәйгедә катнашу өчен ниләр каршылык булып тора ала соң? Проектның Нигезләмәдәге 1.7, 1.8 нче пунктлардагы шартларга туры килмәве буенча яраксыз дип табылуы, проектны әлеге Нигезләмәдәге 1.5 нче пунктта күрстелгән вакытта тапшырмау.

2.5. Грантка дәгъва кылучылар бәйгегә узмый икән, аларга бу хакта Нигезләмәнең 2.4. нче пункты нигезендә 3 эш көне дәвамында, проектлары ТР ДАК документлары арасында кергән хатлар арасында теркәлгәннән соң, хәбәр ителә. Грантка дәгъва кылучыларның документларын кабул итү тәртипләре һәм кагыйдәләре Нигезләмәнең 2.2., 2.3  нче пунктларында күрсәтелгән.

## III. Проектларны халык алдында яклау тәртибе

3.1. Проектларны яклау вакыты, урыны һәм графигы ТР ДАК Боерыгы аша игълан ителә һәм Грантка дәгъва кылучыларга әлеге Нигезләмәнең 1.5. нче пункты нигезендә ТР ДАК сайтына 7 эш көненнән дә соңгарак калмый урнаштырыла.

3.2. Проектны яклау муниципаль архив җитәкчесе яисә аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан башкарыла.

3.3. Яклауга 10 минут вакыт бирелә.

## IV. Проектларны бәяләү тәртипләре һәм критерийлары

4.1. Муниципаль архивларның проектларын бәяләгәндә, алар түбәндәгеләр белән тәэмин ителә:

- килгән материалларга карата анык һәм гадел фикердә булу,

- материалларны читкә чыгармау.

4.2. Грантка дәгъва кылучыларның проектларын бәяләү Экспертлар советы әгъзалары тарафыннан тиешле критерийлар нигезендә бәя кую юлы белән башкарыла.

4.3. Экспертлар советы әгъзалары критерийлар буенча куелган балларны туплый, аларны суммалаштыра.

4.4. Баллар экспертларга таратылган битләргә теркәлә, Экспертлар советы рәисенә тапшырыла.

4.5. Бәя бирү критерийлары түбәндәгечә:

- эшнең актуальлеге һәм социаль әһәмияте (1 дән 10 баллга кадәр);

- чараларны уздыруга программалы һәм максатчан якын килү (1 дән 10 баллга кадәр);

- проектның масштабы, нәтиҗәләренең колачы (1 дән 10 баллга кадәр);

- проектның методик яктан эшләнеше, ТР башка муниципаль архивларында да тормышка ашыру мөмкинлеге (1 дән 10 баллга кадәр);

- проектның алга таба тормышка ашыруның перспективалары (1 дән 15 баллга кадәр).

4.6. Балларны бергә туплаганнан соң, Экспертлар советы әгъзалары, әлеге Нигезләмәнең 4.5. нче пунктына таянып, Грантка дәгъва кылучыларның нәтиҗәләре рейтингын формалаштыра, ул рейтинг рәис һәм әгъзалар кулы белән расланган булырга тиеш.

4.7. Баллар бертигез булган очракта, сайланган дәгъвачыларга өстәмә критерийлар куела (алар Татарстан Республикасы ведомствоара Бердәм электрон документ әйләнеше системасы аша ТР ДАК на килеп кергән муниципаль архивларның 2019 елгы еллык отчетларына карап булдырыла). Бу критерийлар муниципаль архивка проектын уздырганда ярдәм итә ала:

- алдагы елда план күрсәткечләрен үтәүнең зур күләмдә булуы;

- 2020 елның 1 гыйнварына кадәр саклаган документлар күләменең зур булуы;

- 2020 елның 1 гыйнварына кадәр комплектлау чыганаклары күләменең зур булуы.

## V. Экспертлар советын һәм аның эшчәнлеген формалаштыру

5.1. Экспертлар советы архив эше буенча белгечләрдән туплана, күләме, рәис һәм аның урынбасары, әгъзаларның үзләре белән бергә исәпләгәндә, 9 кешене тәшкил итә.

5.2. Экспертлар советы составы ТР ДАК рәисе Боерыгы белән раслана.

## VI. Бәйге җиңүчеләрен һәм аларны бүләкләү рәвешен билгеләү

6.1. Грантка дәгва кылучылар проектларын халык алдында яклаганнан соң 3 эш көне узгач, Экспертлар советы, рейтингны күздә тотып, бәйгедә җиңүчеләрнең исемлеген төзи.

Җиңүчеләр дип әлеге Нигезләмәнең 1.6. нчы пункты нигезендә «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклау

буенча проектларга ярдәм итү» номинациясендә бәйге сайлавын узып, 1 дән алып 7 нче урынга кадәр чыккан, ә «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын популярлаштыру һәм куллану буенча проектларга ярдәм итү» номинациясендә 1 дән алып 8 нче урынга кадәр урыннарга чыккан проектлар игълан ителә.

6.2. Экспертлар советы карары алар өчен күпчелек тавыш биргән очракта кабул ителә. Әгәр тавышлар бертигез икән, хәлиткеч тавыш дип Экспертлар советы рәисе тавышы исәпләнә.

6.3. Экспертлар советы утырышы тулы вәкаләтле дип анда гомуми саннан 3/2 өлеше катнашса санала.

6.4. Экспертлар советы карарлары протоколда теркәлеп бара.

6.5. Бәйгедә җиңүчеләр исемлеге – Грантны алучылар исемлеге ТР ДАК рәисе тарафыннан Боерык белән раслана. Аның нигезләмәсе – Экспертлар советының йомгаклау утырышыннан соң 3 көн узганнан соң протоколга кул куелу.

6.6. Боерыкка кул куелганнан соң 3 эш көне дәвамында Боерык ТР ДАК сайтында урнаштырыла (www.http://arhiv.tatarstan.ru/).

6.7. Бәйгегә кабул ителгән проектлар муниципаль архивларның җитәкчеләреннән килгән гариза нигезендә 31 декабрьдән дә калмый кайтарыла.

## VII. Грант отучыларның отчет бирү тәртипләре һәм сроклары

7.1. Грант отучылар һәр елны, 3 ел дәвамында, ТР ДАК на җиһазлар һәм җайланмаларны тиешле максатта куллanулары хакында отчет биреп бара, отчет елы дип исәпләнгән елның чираттагысында, 1 июньгә кадәр тапшырылырга тиешле.

7.2. Отчетта эшчәнлекне яктырту зарур, түбәндәге төп позицияләр турында язу әһәмиятле:

1) проектның томышка ашырылуын тасвирлау;

«Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклау буенча проектларга ярдәм итү» номинациясендә:

- Россия Федерациясе Архив фонды документларының һәм башка архиф документларының электрон фонд булдыру барышында никадәре цифрага күчерелгән – күләмент күрсәтү;

- Россия Федерациясе Архив фонды документларының һәм башка архиф документларының электрон фонд булдыру барышында никадәр цифрага күчерелгән документ атрибуция узган;

- Татарстан Республикасы Бердәм архив мәгълүмати системасына ничә документның электрон нөсхәсе урнаштырылган;

«Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын популярлаштыру һәм куллану буенча проектларга ярдәм итү» номинациясендә:

- Ничә чара электрон фонд документларын кулланып уздырылган, электрон фондка мөрәҗәгать иткән тикшеренүчеләрнең исәбе;

- архив документларын эзләп мөрәҗәгать иткән гражданнарның исәбе һәм аларның ихтыяҗын фонд хисабы ярдәмендә тәэмин итүне оештыру соркларын;

Барлык номинацияләрдә дә:

- Җәмәгатьчелек фикерен туплап җиткерү (СМИ, анкеталар);

- фото-, видеоматериаллар.

2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларының грант ярдәме отар өчен бәйге Нигезләмәсенә Кушымта

2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларының
грант ярдәме отар өчен бәйгедә катнашу өчен гаризасы

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Проектның исеме | |
| 2 | Номинациясе | |
| 3 | Муниципаль архивның тулы исеме (алга таба – оешма) | |
| 4 | Муниципаль архивның җитәкчесе (ФИО) | |
| 5 | Муниципаль архивның тулы адресы | |
| 6 | Контакт өчен телефон, e-mail | |

Татарстан Республикасы муниципаль районы
(шәһәр округы) башкарма комитеты (идарәсе)
Җитәкчесенең ФИО: ______________________________________________________

Гариза тутырылган көн (дата): _________________________________________________